БИШЕНЧЕ ЧАКЫРЫЛЫШ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИШЕЕВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

# КАРАРЫ

2026 ел, 14 сентябь № 16

## Апас муниципаль районы Ишеево авыл җирлеге Советы депутаты статусы турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы «Җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль канун нигезендә, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Ишеево авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Ишеево авыл җирлеге Советының 2021 елның 9 августындагы «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Ишеево авыл җирлеге Советы депутаты статусы турындагы нигезләмә хакында»гы 28 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Ишеево авыл җирлеге Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) преамбуладагы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль канунның 40 нчы маддәсе белән” дигән сүзләрне “Бердәм хакимият системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” “2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль канун” дигән сүзләр белән алыштырырга.;

2) 2 нче маддәнең беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“Депутатның вәкаләтләр вакыты биш ел тәшкил итә.”

3) 3 нче маддәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«3 нче маддә. Депутат вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату
1. Депутат вәкаләтләре түбәндәге очракларда вакытыннан алда туктатыла:
1) вафат булу;
2) үз теләге белән отставкага китү;
3) суд тарафыннан эшкә сәләтсез яки эшкә сәләте чикле дип танылу;
4) суд тарафыннан хәбәрсез югалган дип танылу яки үлгән дип игълан ителү;
5) аңа карата судның гаепләү карары канунлы көченә керү;
6) Россия Федерациясе чикләреннән читкә даими яшәү урынына чыгып китү;
7) Россия Федерациясе гражданлыгын туктату яки чит дәүләт гражданлыгы (подданствосы) булу, яисә чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы яшәү рөхсәте яки башка документ булу;
8) тиешле җирле үзидарә органы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату;
9) хәрби хезмәткә чакырылу яки аны алмаштыручы альтернатив гражданлык хезмәтенә җибәрелү;
10) чит ил агенты статусын алу;
11) әлеге Федераль канун һәм башка федераль кануннар белән билгеләнгән башка очраклар.

2. Депутатның вәкаләтләре, Россия Федерациясенең коррупциягә каршы тору турындагы кануннарында билгеленгән чикләүләрне, тыюларны үтәмәгән, бурычларны башкармаган очракта, вакытыннан алда туктатыла, әгәр «Бердәм хакимият системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль канун белән башкасы каралмаган булса.

3. Депутатның вәкаләтләре, депутат алты ай дәвамында рәттән Советның барлык утырышларында хөрмәтле сәбәпләрсез булмаган очракта, Совет карары белән вакытыннан алда туктатыла.

4. Совет тарафыннан депутат вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында карар кабул ителгән депутат, әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән алып 10 көн эчендә, әлеге карарга шикаять белдереп, судка мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

5. Әгәр дә, Советның депутат вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турындагы карары нигезендә вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган булса, депутат әлеге карарны суд тәртибендә шикаять итсә, Совет суд карары канунлы көченә кергәнче Совет депутатларының өстәмә сайлауларын билгеләү турында карар кабул итәргә хокуклы түгел.

6. Депутатның вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турындагы Совет карары, вәкаләтләрне туктату өчен нигез барлыкка килгән көннән алып 30 көннән дә соңга калмыйча, ә әгәр бу нигез Совет сессияләре арасындагы чорда барлыкка килсә — әлеге нигез барлыкка килгән көннән алып өч айдан да соңга калмыйча кабул ителә.

7. Әгәр дә, Совет тарафыннан депутатның вәкаләтләрен әлеге маддәнең 1 нче пунктының 2 нче пунктчасында каралган нигез буенча вакытыннан алда туктату турындагы карар әлеге маддәнең 6 нчы өлешендә каралган срокта кабул ителмәсә, депутат процессуаль кануннарда каралган тәртиптә Советның эшсезлегенә зарланып (шикаять белән) судка мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

8. Татарстан Республикасы Рәисе депутат вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында гариза белән мөрәҗәгать иткән очракта, вәкаләтләрне вакытыннан алда туктату өчен нигез барлыкка килгән көн булып әлеге гаризаның Советка кергән көне санала.»;

4) 5 нче маддәдә

а) 4 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Совет депутаты бер үк вакытта башка муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты яки башка муниципаль берәмлек башлыгы вәкаләтләрен башкара алмый, 2025 елның 20 мартындагы «Җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 33-ФЗ номерлы Федераль канун һәм башка федераль кануннар белән билгеләнгән очраклардан тыш.»;

б) 5 нче пунктта «җирле үзидарә сайлау органы әгъзалары, җирле үзидарә сайлаулы вазыйфаи затлары» дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

в) 6 нчы пункттагы «Депутат, җирле үзидарә сайлау органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайлап куела торган вазыйфаи заты җаваплылыкка тартылырга мөмкин түгел» дигән сүзләрне «Депутат җаваплылыкка тартылырга мөмкин түгел» дигән сүзләр белән алыштырырга;

5) 7 нче маддәнең 3 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Депутатның сайлаучылар белән очрашулары Россия Федерациясенең җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, йөрешләр һәм пикетлар турындагы кануннары нигезендә үткәрелә.

Җирле үзидарә органнары депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын үткәрү өчен махсус билгеләнгән урыннарны, шулай ук җирле үзидарә органнары тарафыннан депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын үткәрү өчен бирелә торган биналар исемлеген һәм аларны бирү тәртибен билгелиләр.»;

б) 10 нче маддәдә

а) 2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Депутат Россия Федерациясенең коррупциягә каршы тору турындагы кануннарында билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәргә һәм бурычларны башкарырга тиеш.»;

б) 6 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Үзенең, шулай ук иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүматлар биргән депутатларга карата, әгәр бу мәгълүматлардагы хаталар әһәмиятсез булса, җаваплылыкның түбәндәге чаралары кулланылырга мөмкин:

1) кисәтү;

2) депутатны тиешле җирле үзидарә органындагы вазыйфасыннан азат итү һәм аның вәкаләтләре тәмамланганчыга кадәр тиешле җирле үзидарә органында вазыйфалар биләү хокукыннан мәхрүм итү;

3) даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашырудан азат итү һәм аның вәкаләтләре тәмамланганчыга кадәр даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру хокукыннан мәхрүм итү;

4) вәкаләтләре тәмамланганчыга кадәр тиешле җирле үзидарә органында вазыйфалар биләүне тыю;

5) вәкаләтләре тәмамланганчыга кадәр даими нигездә вәкаләтләрне башкаруны тыю.»;

в) 7 нче пунктта «җирле үзидарә сайлаулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайлаулы вазыйфаи затына» дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

г) 9 нче пунктта «җирле үзидарә сайлаулы органы әгъзасы, җирле үзидарә сайлаулы вазыйфаи заты,» дигән сүзләрне төшереп калдырырга, «гамәлгә ашыручылар» сүзен «гамәлгә ашыручы» сүзенә алмаштырырга»;

д) 8 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатның түбәндәгеләргә хокукы юк:

1) шәхсән яки ышанычлы затлар аша эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнү;

2) түбәндәге очраклардан тыш, коммерция яки коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашу:

а) Сәяси фиркане, һөнәри берлек органын, шул исәптән җирле үзидарә органында төзелгән башлангыч һөнәри берлек оешмасының сайлап куела торган органын идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләре ширкәтенең съездында (конференциясендә) яки гомуми җыелышында катнашу;

б) коммерцияче булмаган оешманы идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу (сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында төзелгән башлангыч һөнәри берлек оешмасының сайлап куела торган органы, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек хуҗалары ширкәтенең съездында (конференциясендә) яки гомуми җыелышында катнашудан тыш) Татарстан Республикасы кануны белән билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Рәисен алдан хәбәрдар итү юлы белән башкарыла;

в) Җирлек мәнфәгатьләрен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр советында, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында бушлай нигездә тәкъдим итү;

г) Җирлекнең гамәлгә куючысы (акционеры, катнашучысы) булып торган оешманың идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә Җирлек мәнфәгатьләрен бушлай нигездә тәкъдим итү, бу эш Җирлек исеменнән оешманың гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен яки муниципаль милектә булган акцияләрне (устав капиталындагы өлешләрне) идарә итү тәртибен билгеләүче муниципаль хокукый актларга нигезләнеп башкарыла;

д) федераль кануннарда каралган башка очраклар;

3) укыту, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлектән тыш, башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнмәскә. Шул ук вакытта укыту, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек, әгәр дә Россия Федерациясенең халыкара килешүендә яки Россия Федерациясе кануннарында башкасы каралмаган булса, чит ил дәүләтләре, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм ватандашлыгы булмаган затлар исәбенә генә финансланырга тиеш түгел;

4) чит ил коммерцияче булмаган, хөкүмәткә карамаган оешмаларның һәм Россия Федерациясе территориясендә эшләүче аларның структур бүлекчәләренең идарә органнары, попечительләр яки күзәтү советлары, башка органнары составына керү (әгәр Россия Федерациясенең халыкара килешүендә яки Россия Федерациясе кануннарында башкасы каралмаган булса).».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм мәгълүмати стендларда бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җирлек Башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Апас муниципаль районы
Ишеево авыл җирлеге Башлыгы — Р.Р. Сатдинов